Милләтләр мәктәбе

Тел бетсә, милләт тә югала. Нинди генә милләттән булуыңа карамастан, туган телеңне кадерләп сакларга, аны үстерергә кирәк. Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында эшләп килгән күпмилләтле якшәмбе мәктәбенең дә төп бурычы шуннан гыйбарәт.

4 БИТ

Эшне сөйсәң – үз анаң...

«Бер урында шуның кадәр эшләп буламыни, шуңа өстәп, заводта, дип сорыйлар. Эшне сөйсәң – үз анаң, сөймәсәң – үги анаң, диләрме әле? Яратмаган эштә бер көн дә торып булмый, ә без – үз эшебезнең фанатлары», – диләр ирле-хатынлы Хәсбиуллиннар.

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Сишәмбе | 4.04.2017 | №35 (5797)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ХЕЗМӘТ ИТЕП КАЙТЫРГА ЯЗСЫН!

АРМИЯ

Россиядә армиягә язгы чакырылыш башланды. Чакырылыштагы хәрби хезмәткә 1990-1999 елларда туганнар алына. Хезмәт итү срогы – бер ел.

Дамир БӘДРИЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

– Татарстанда апрельдән башлап, июль ае ахырына кадәр 19 мең кеше медицина комиссиясе узачак, шулардан 4 меңгә якыны хәрби частьларга җибәреләчәк, – дип хәбәр итте республика хәрби комиссары Сергей Погодин «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында оештырылган матбугат конференциясендә.

Урта һөнәри белем алучы егетләргә 2017 елның 1 гыйнварыннан бирелгән кичектереп тору хокукы уку чоры тәмамланганчы гамәлдә. Армиягә чакырылыш хезмәтенә алынучыларның күпчелеген югары белеме яки урта һөнәри белгечлеге булганнар тәшкил итәчәк. Сергей Погодин әйткәнчә, «С» һәм «Д» категорияләрендәге йөртүчеләр, БТР-80, шулай ук МТЛБ механик-йөртүчеләре, укчы-парашютчылар, ягъни хәрби-хисап белгечлеге үзләштергән 711 ир-егет, хәрби хезмәт узу өчен, үзе теләгән частьны сайлап ала.

Армиягә чакырылыш хәрби хезмәтенә алынучыларга шәхси гигиена тупланмасы бүләк ителә. Татарстан хөкүмәте тарафыннан моңа кадәр кәрәзле телефон да бүләк ителә иде. Кызганыч, бу хәйрия чарасы беткән. Республика быелның языннан «Позвони маме» федераль проектында катнаша. Сергей Погодин аңлатканча, чакырылыштагы хәрби хезмәткә алынучыга һәм аның ата-анасына бушлай сим-карта бирелә. МТС, Билайн яки Теле 2 элемтә операторларының берсен сайларга кирәк. Ташламалы тарифлар тәкъдим ителә. Телефон элемтәсе өчен тәүге 100 сумны республика түли. Сим-карталар чакырылыштагы хәрби хезмәткә алынучыларга республика шәһәрләренең һәм районнарының чакырылыш пунктларында бирелә.

– Ятимнәргә кәрәзле телефон бүләк ителә. Аларга ул республиканың «Патриот» җыелу пунктында тапшырыла. Чакырылыштагы хәрби хезмәткә алынучыларга шул ук пунктта банк карталары да бирелә. Хәрби хезмәте чорында солдатларга ай саен – 2000 сум, ятимнәргә – 3000 сум, сержантларга 4000 сум күчереп барыла. Бу картага ата-аналар һәм туганнары да акча күчерә ала. Контрактта хәрби хезмәт срогын ике-өч елга билгеләргә була. Контракттагыларның айлык хезмәт хакы – 20-70 мең сум. Камчаткада, мәсәлән, су асты көймәсендә контракт буенча хезмәт итсәң, 70 мең сум түләнә, – диде Сергей Погодин. – Хатын-кызлар, хәрби хезмәткә чакырылмый. Теләкләре булган хатын-кызлар, хәрби училищеларда элемтә, медицина белгечлекләре үзләштереп, армиягә бара ала. Чакырылыштагы хәрби хезмәттәгеләр Сүриягә җибәрелми, анда контракттагылар гына бара.

Республика хәрби комиссары әйткәнчә, узган елгы чакырылыштагы якташларыбыз хәрби дисциплинаны бозмаган, башкалар тарафыннан кыерсытылмаган.

Казан гарнизоны Хәрби прокуратурасы «кайнар элемтә» телефоны – **(843) 264-23-51,** атнаның эш көннәрендә 9.00-18.00 сәгатьләрдә; Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты «кайнар элемтә» телефоны – **(843) 221-60-06,** атнаның эш көннәрендә 9.00-18.00 сәгатьләрдә; Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының тәүлек буена эшләүче кыска санлы «кайнар элемтә» телефоны – **05216.**

Илдар Халиков:
«Иртәрәк тә киткән булыр идем»

Татарстан премьер-министры Илдар Халиков, башка эшкә күчү сәбәпле, үз теләге белән эшеннән китте. Аның яңа вазифасы да билгеле булды, «Татэнерго» идарә компаниясе» акционерлык җәмгыяте директорлар советы, җәмгыятьнең бердәнбер акционеры – «Связьинвестнефтехим» тәкъдимен бертавыштан хуплап, 2017 елның 4 апрелендә Илдар Халиковны компаниянең генераль директоры итеп билгеләде.

Илдар Халиковның отставкага китүен күпләр «Татфондбанк» тирәсендә барган вазгыять белән бәйләп карый. Әмма ул «БИЗНЕС Online»-га, әлеге хәл килеп чыкмаган булса, мин Яңа елга кадәр үк эштән киткән булыр идем, дип белдергән.

– Әлбәттә, «Татфондбанк» белән бәйле вазгыять өчен мин дә җаваплы. Күпләр, мөгаен, китүемне шул соңгы вакыйгалар белән бәйләп карыйдыр. Алдамыйм: бу карар күптән туган иде. Банк белән булган хәлләр аркасында эштән китүем соңрак булды. Без «Татфондбанк»ны коткарып калу өчен, бөтенесен дә эшләргә тырыштык. Отставкага китүем – тулысынча үз теләгем белән. Бу хәлләр булмаса, Яңа елга кадәр үк киткән булыр идем. Эшчәнлек төрен һәр биш-җиде ел саен алыштырып торырга кирәк дип юкка гына әйтмиләр. Мин премьер-министр булып җиде ел эшләдем. Ничек кенә булса да, Татарстанда калам. Тәҗрибәм республикага кирәк булыр дип уйлыйм, – дигән ул «БИЗНЕС Online» журналистына.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы икенче кандидат билгеләгәнче, премьер-министр вазифаларын премьер-министрның беренче урынбасары Алексей Песошин башкарачак.

Казан метросында һәр пассажир тикшерелә

Кичә Санкт-Петербургта «Сенная площадь» белән «Технология институты» метро станцияләре арасында вагон шартлады. Җир асты вестибюлен төтен каплаган, 50гә якын кеше зыян күргән, ун кешенең гомере өзелгән дип хәбәр итә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы.

Вагонда поезд кузгалып киткәнче үк шартлаткыч матдә куелган дигән фикер дә бар. Россия Президенты Владимир Путин исә, шартлауның сәбәпләрен бары тикшерү нәтиҗәсендә генә ачыкларга мөмкин булачак, диде. Ул фаҗигадә зыян күрүчеләрнең якыннарының тирән кайгысын уртаклаша. Санкт-Петербург прокуратурасы тикшерү эшләре белән мәшгуль.

Петербургтагы фаҗига белән бәйле рәвештә, «Казан» аэропортында, тимер юлы станцияләрендә, Казан метросында да куркынычсызлык хезмәте көчәйтелгән.

– Полиция хезмәткәрләрен өйләреннән дә чакырттык. Метрода һәр кешене, багажларны тикшерәчәкләр, – ди «Метроэлектротранс» берләшмәсе генераль директорының куркынычсызлык буенча урынбасары Мөхәммәт Сәмигуллин.

Казан метро станцияләрендә болай да куркынычсызлык мәсьәләсенә зур игътибар бирелә. Платформаларда видеокүзәтү камералары куелган, иртән эт белән кинологлар составны тикшереп чыга.

СОЦИАЛЬ КАЙГЫРТУ

Казанда күпбалалы гаиләләргә бушлай өләшү өчен тагын 4800 җир кишәрлеге билгеләнгән. Аларны гаиләләргә бирү эшенә Сокуры авылы янында – 24 апрельдә, ә Каймар авылы янында май башыннан керешәчәкләр.

Өченче бала – җир кишәрлегенә соңгы «казык»

– Башкала янәшәсендәге Олы Дәрвишләр һәм Константиновка бистәләрендә, шулай ук Биектау районындагы Дачный белән Красносельск авыл җирлекләрендә дә 2800 җир кишәрлеге билгеләнде, – дип хәбәр итте кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә шәһәр Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр комитеты рәисе Ренат Галәветдинов.

– Узган елның октябрендә дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булганнарга – Олы Дәрвишләр бистәсе янынннан 36 кишәрлек, ә биш һәм аннан да күбрәк балалыларга Константиновка авылы янынннан 13 кишәрлек бирелде. Биредә җир кишәрлекләре бүлеп бирү дәвам итәчәк. Дачный белән Красносельск авыллары янында җир кишәрлекләрен бүлү сентябрь-октябрь айларына планлаштырылды.

Федераль программа нигезендә, Казанда күпбалалы гаиләләрне бушлай җир кишәрлекләре белән тәэмин итү 2011 елда башланды. Беренче елны исемлеккә 1158 гаилә теркәлгән булса, хәзер әлеге сан 9425кә җитте.

– Күпбалалы гаиләләргә бушлай җир кишәрлеге бирү программасы дәвам итә. Киләчәктә күпбалалы гаиләнең теге яки бу торак пунктында теркәлеп, биш ел даими яшәве шарт итеп куелырга мөмкин. Әлегә мондый таләп юк, – диде Ренат Галәветдинов.

Сокуры һәм Каймар авыллары янәшәсендә икешәр мең йортлы булачак бистәләрнең проектлары әзерләнгән. «Казан электр челтәре» предприятиесе Каймар авылы янәшәсендәге кишәрлекләргә электр линиясе сузган. Ренат Галәветдинов сөйләгәнчә, булачак бистәләрдә су, газ үткәргечләр сузу, юллар төзү кебек инженерлык эшләрен шәһәр һәм республика бюджетларына гына «җиңеп чыгу» мөмкин түгел. Моның өчен федераль программа зарур.

– Шәһәр Башкарма комитеты булышлыгында, күпбалалы гаиләләрнең җир кишәрлекләре шәхси милек сыйфатында теркәлде. Тагын 99 гаилә документлар тутыру белән үзләре шөгыльләнә. Күпбалалы гаиләләр үзләренең җир кишәрлекләрен башкаларга арендага бирергә яки сатып җибәрергә хокуклы, моны тыя торган закон юк, – диде Ренат Галәветдинов.

Казан мэры Илсур Метшин үзенең фикерләре белән уртаклашканда, күпбалалы гаиләләргә бушлай җир кишәрлекләре бүлеп бирү зур социаль әһәмияткә ия программа, дип бәяләде.

– Башкалада күпбалалы гаиләләр саны 2011 елдан соң сигез мәртәбәгә артты, – диде мэр Илсур Метшин.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр сайтында **https://uslugi.tatar.ru** шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр комитеты сайтында **http://www.kzio.kzn.ru/section/12** электрон гариза тапшырырга, чиратның хәрәкәтен күзәтеп барырга була.

Дамир БӘДРИЕВ.

Акыл ияләрен Иннополис шәһәрендә фатир көтә

Март аенда Иннополиста аренда торак йортларының беренче чираты төзелеше тәмамланган. Биредә 840 фатирга исәпләнелгән 16 аренда йорты сафка басачак. Төзелешләрнең заказчы-инвесторы – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды.

– Иннополиста торак төзелешендә Татарстанда җитештерелгән сыйфатлы бетон, кирпеч, гипс кулланыла. Пыяла – «Алабуга» үзгә икътисади зонасында эшләүче Төркия фирмасыннан, – диде республиканың төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары Юрий Аляшев «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат конференциясендә. – Аренда торак йортлары җир асты «автомәйданчыгы» белән төзелә. Беренче катта – коммерция максатларындагы торак булмаган мәйданнар. Йортлар электрон ачкычлар, үзәкләштерелгән кондиционер, ягъни һава алмаштыру челтәре, фатирлардагы һәм гомумйорт хисаплагычларындагы күрсәткечләрне автомат рәвештә ерак арадан хисаплау аппаратлары белән җиһазландырылган. Фатирларга йорт җиһазлары куелган.

Иннополиста аренда торагына ихтыяҗ зур булуын исәпкә алып, Татарстан хөкүмәте узган елның октябрендә аренда торак йортларының икенче чираты төзелешен башлау турында карар чыгарган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов раслаган проект буенча Иннополиста ел ахырына кадәр тугыз катлы алты йорт җиткезеләчәк. Аларның беренче катларын автомәйданчыклар тәшкил итә.

Иннополиста коммерция тәртибендәге торак йортлар төзелеше планнары да уйланыла. Шәһәр инженерлык челтәрләре, транспорт, балалар бакчалары, IT-лицей, спорт һәм медицина үзәкләре белән тәэмин ителгән. Иннополис федераль университеты, студентларның торак кампуслары, А.С.Попов исемендәге административ эшлекле үзәк уңышлы эшли.

Рәдиф КАРАГАЙ.

Дамир Бәдриев фотоархивыннан

Ятимнәр фатирлы булды

www.tatar-inform.ru

Кичә Лаеш районының Комлы Кавал авылында ятим балаларга фатирлар тапшырылды. Инде кайберләренең үз балалары булган 15 кешегә яңа торак ачкычлары бирелде. Бу тантаналы чарада катнашкан Татарстанның мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов әйтүенчә, ятим балаларны торак белән тәэмин итү программасы 2020 елга кадәр исәпләнгән. Бүгенгә республика буенча әти-әнисез үскән тагын 1000нән артык бала «өй туе» көтә.

Ятим балалар, әти-әнисез үскәннәр өчен 2017 елда торакка акчаның 302 844 меңе – Татарстан бюджетыннан, 43 880,6 меңе федераль казнадан бүленеп бирелгән. Ятимнәргә йортлар биш елга найм килешүе нигезендә тапшырыла. Бу фатир хуҗаларын төрле ялган килешүләр, «кара» риэлторлардан саклау өчен дә эшләнә. «Северный» микрорайонында төзелгән биш катлы ике йорт «Социаль ипотека» программасы буенча төзелгән. Монда ятим балалардан тыш, программада катнашучы предприятие хезмәткәрләре, Бөек Ватан сугышы ветераннары, бюджет өлкәсендә эшләүчеләр дә яшәячәк.

Быелдан башлап мәктәп программасына астрономия кертеләчәк, яңа фәнне физика укытучылары алып барачак, аңа өстәмә сәгатьләр бүленмәячәк, дип җиткергән дүшәмбе көнне Россия мәгариф һәм фән министры Ольга Васильева. Бу хакта «Интерфакс»ка сылтама белән «Татар-информ» агентлыгы яза.

Мәктәпкә астрономия фәне кайта

«Монда гаҗәпләнерлек берни дә юк – астрономия физика курсында укытыла иде, безнең уку әсбаплары бар, алар һәрвакыт федераль исемлектә булды. Физика укытучылары моңа әзер, алар инде физика фәне кысаларында түгел, әлеге курсларны астрономия итеп аерым алып барачак. Сәгатьләр буенча берникди үзгәрешләр булмый», – диде Васильева Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы утырышында.

Бер ел алдан Роскосмоста Россия Мәгариф һәм фән министрлыгыннан мәктәпләргә астрономияне кайтару турында сораганнар иде.

mosday.ru

АЛАР ВЕРТОЛЁТ ТӨЗИ

Заводта эшләүче яшьләрнең көне станок артында гына үтә, дип уйласагыз, ялгышасыз. Алар әле җырларга, биергә, спорт белән шөгыльләнергә дә вакыт таба. Яшьләргә актив тормышта кайнарга Завод яшьләре берлеге дә ярдәм итә. Бу көннәрдә берлек 25 еллыгын билгеләп үтте.

Алисә САБИРОВА

Юбилей чарасы Авиатөзелеш районының «Крылья Советов» паркында урнашкан Ленин мәдәният йортында узды. Исегездә булса, бу паркны төзекләндерү өчен завод 85 миллион сум акча бүлеп биргән иде. Тиздән мәдәният йорты да яңартылачак.

Заводта 5-6 мең кеше эшләсә, шуларның 35 процентын яшьләр тәшкил итә. Берлеккә 17-35 яшьлекләр керә. Ләкин 35 яшьтән соң да яшь белгечләр югалып калмый. Карьера үсеше мөмкинлеге яшьләрне тагын да тырышып эшләргә илһамландыра. Заводның яшьләр берлеге советы иҗтимагый оешмасы рәисе Татьяна Колебанова белдергәнчә, иҗатта актив яшьләр станок янында да югары күрсәткечләргә ирешә.

– Яшьләргә төрле яктан ярдәм кулы сузарга тырышабыз. Әйтик, армиядәге егетләргә, декрет ялындагы хатын-кызларга акчалата ярдәм итәбез. Яшьләрнең спорт белән шөгыльләнәселәре килсә, фитнес клубка алган абонемент бәясенең, белгечнең стажына карап, 70-50-30 проценты түләнә. Заводның һәр эшчесе торак хәлләрен яхшырту өчен социаль ипотека һәм «Вертолеты России» холдингы программасыннан файдалана ала. Эшчеләргә ипотеканың беренче кертемен түләү өчен 1 миллион 300 мең сум акча бүленеп бирелә. Бу сумма заводка кире кайтарылмый. Бары тик эшче заводта биш-җиде ел эшләргә тиеш дигән шарт куела, – ди Татьяна Колебанова.

Яшьләр берлеге үзенчә комсомоллар хәрәкәтен алыштырган. Төп максаты – яшьләрне берләштерү, сәнагатькә җәлеп итү.

Валерий Соломахин фотосы

Евгений Сороколетов инде өченче ел заводта җайланмаларны төяү буенча белгеч булып эшли.

– Мин һәрвакыт авиация белән кызыксындым. Үземне Казан вертолет заводында сынап карарга булдым. Эшкә урнашу авыр дип әйтмәс идем, барысы да кешенең мөмкинлегеннән тора. Заводның кадрлар сәясәте сәләтле яшь белгечләргә эшкә урнашырга ярдәм итә. Эшемнең нидән гыйбарәт булуын сезгә сөйли алмыйм, чөнки ул хәрби сәнәгать белән бәйле. Эш белән генә түгел, иҗат белән дә яшибез. Заводның яшьләр берлегендә мин рәсем ясыйм. Россиядә дә, чит илләрдә дә инженерлар һәрвакыт югары бәяләнә. Бу – билгеле бер статус. Инженер һәрвакыт үсештә, ни дә булса уйлап таба, – ди яшь белгеч.

Гөлназ Кәбирова исә дүрт ел элек заводта практика узган вакытта эшкә урнашып кала.

– Мин завод хезмәткәрләрен сакчыл җитештерүгә өйрәтәм. Чыгымнарны киметеп, керемне арттыруга юнәлтелгән эш бу. Предприятиедәге процессларны камилләштерүдә кайбер технологияләрне яңартабыз, – ди Гөлназ.

Вертолет заводы – үткәнне онытмыйча, киләчәккә йөз тоткан оешма. Заводның булачак белгечләрен инде мәктәп партасыннан ук үстерүе моның бер мисалы. Казанның 54нче мәктәбендә һәм 8нче гимназиясендә вертолет сыйныфлары эшли. Мәктәп укучыларын вертолет төзү серләренә өйрәтүне заводның генераль директоры Вадим Лигай үз кулына алган.

vk.com

БЕЗ БЕРГӘ

Майя Хухунашвили:

«Татарстанда милли сәясәт өлкәсендә бай тәҗрибә тупланды»

Тел бетсә, милләт тә югала. Нинди генә милләттән булуыңа карамастан, туган телеңне кадерләп сакларга, аны үстерергә кирәк. Татарстанның Халыклар дуслыгы йортында эшләп килгән күпмилләтле якшәмбе мәктәбенең дә төп бурычы шуннан гыйбарәт. Якшәмбе мәктәбе директоры Майя Хухунашвили белән әңгәмәбез шул хакта.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Майя Мануиловна, күпмилләтле якшәмбе мәктәбе кайчан һәм ничек оешты?

– Узган елны мәктәбебез 20 еллыгын билгеләп үтте. Ул I Татарстан халыклары съезды нәтиҗәсе буларак оешты дип әйтергә була. Корылтай төрле халыкларның милли-мәдәни автономияләре алдына туган телләрен өйрәнү, саклау бурычын куйды. Аңа кадәр шәхси башлангыч нигезендә туган телне өйрәнү буенча берничә бүлек кенә эшли иде. Без исә аны аерым бер мәгариф структурасы итеп үстерергә булдык. Бүгенге көндә күпмилләтле якшәмбе мәктәбендә 17 милли бүлек эшли. Гомумән алганда, аларның саны – 22, биш бүлек иҗади юнәлештә эшләп килә. Укучыларыбызның саны 400гә җитте. Мәктәп өстәмә белем бирү системасына кергән, мәктәпнең гамәлгә куючысы – Казан шәһәре мәгариф идарәсе. Бездә уку – түләүсез.

– Татарстан халыклары ассамблеясы составында бүген 36 милли-мәдәни оешма барлыгын истә тотканда, бөтен милли оешманың да уку бүлеге әлегә юк булып чыга...

– Кызганычка, шулай. Ачылган бүлекләр дә кайвакыт эшләп китә алмый. Йә балалар йөрми, йә аларны укытырга педагоглар табып булмый. Бу эшне милли оешмалар хәл итәргә, ата-аналар белән сөйләшүләр алып барырга тиеш. Татарстан халыклары ассамблеясы да, Халыклар дуслыгы йорты да безнең партнерлар булып тора. Мәктәбебез дә Дуслык йортында урнашкан. Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе, Казан шәһәре Башкарма комитетының телләрне үстерү һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр идарәсе белән тыгыз хезмәттәшлектә торабыз. «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстанда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы ярдәмендә дәреслекләр алабыз, матди-техник базабыз яңартылып тора. Фестиваль, бәйгеләр, слетлар уза. Ел саен каникул чорында күпмилләтле җәйге лагерь эшли. Узган ел 350 бала ял итте. Анда, күпмилләтле якшәмбе мәктәбе укучыларыннан кала, Татарстан шәһәрләре һәм районнарындагы этно-мәдәни компонентлы һәм күпмилләтле мәктәпләрдә белем алучылар да ял итә. 2007 елдан бирле эшләп килгән лагерьның төп максаты – мәдәниятара диалог, турыдан-туры аралашу ярдәмендә төрле милләт вәкилләренең гореф-гадәтләре һәм мәдәнияте белән танышу.

– Татарстан халыклары ассамблеясы утырышында чыгыш ясаганда, сез, кадрлар проблемасы бар, дип белдергән идегез. Ул проблема ничек хәл ителә?

– Укытучылар коллективы шулай ук күпмилләтле. Барысы да белгечлекләре буенча педагоглар. Элек укытучы итеп телне белгән кешене чакыра идек. Иң мөһим таләп телне белүе иде. Хәзер исә бары тик укытучы белгечлеге алган кеше генә белем бирә ала дигән таләп бар. Читтән чакырып китерә алмыйбыз, бездә аның өчен штат юк. Шуңа да укытучыларыбыз сәгатьләп эшли, хезмәт хакы бик аз, аларга социаль пакет каралмаган. Тулай торак белән дә тәэмин итә алмыйбыз. Шуңа да милли-мәдәни оешма үзенең бүлеген ачарга ниятли икән, беренче чиратта педагог табарга тиеш була. Бу күп кенә оешмалар өчен проблема булып тора, бүлек булдырасылары килә, ә укытучы таба алмыйлар. Икенче бер проблема да бар: укытучысы табылырга да мөмкин, әмма аның якшәмбе көнне аз гына акчага укытасы килми. Бездә эшләүче педагогларның барысының да төп эшләре бар, монда да килеп укыталар. Мин аларны миссионерлар дип әйтәм. Алар үз туган халкы алдындагы миссияне үтиләр. Моны аңлаган кайбер педагогларыбыз Казанның югары уку йортларында укытучы һөнәрен дә үзләштерде. Әйтик, әфган телен укыта торган егетебез белеме буенча юрист, хәзер ул психология һәм педагогика курсларында укый.

– Мәктәпнең кайсы бүлекләре аеруча популяр?

– Чуваш, әзәрбайҗан, грузин, төрек, әфган, гарәп бүлекләре актив эшли, корея бүлеге популяр, аны чит тел буларак та укучылар күп. Быел бурят, вьетнам бүлекләрен ачтык. Украин бүлеге кабат эшли башлады.

– Билгеле бер бүлеккә шул телне, культураны өйрәнергә теләгән башка милләт кешеләре дә йөриме?

– Андыйлар да бар. Күбесенчә алар катнаш гаиләдән булып, тормыш иптәшләренең телен өйрәнергә киләләр. Берәр милләт егетенә гашыйк булган кызлар да йөри безгә. Грузин бүлегенә берничә ел рәттән Грузиягә ял итәргә барган ханым йөри, аны грузин теле, мәдәнияте кызыксындыра. Әтисе бер кечкенә малайны грузин бүлегенә алып килде, үзе милләте буенча – грузин, хатыны татар икән. Кавказ биюләре популяр булганлыктан, аны өйрәнергә 14 төрле милләт баласы йөри.

– Бию дигәннән, сез иҗади чараларда да актив катнашасыз бугай?

– Халыклар дуслыгы йортында узган һәр бәйрәм, концертта катнашабыз. Халыкара туган тел көнен һәр елны билгеле бер тематикага багышлыйбыз. Узган ел грузин шагыйре Шота Руставелиның «Витязь в тигровой шкуре» поэмасына 800 ел булды, шул уңайдан әлеге әсәрне ун телдә укыдык. Быел чуваш шагыйре Петр Хузангайның 110 еллыгын билгеләп үттек. Аның шигырьләрен балалар 14 телдә укыды. Шул рәвешле балаларыбыз башка милләт кешеләре турында да белеп үсә.

– 22 апрельдә узачак зур чара – Татарстан халыкларының өченче корылтае турында искә алмасак, әңгәмәбез тулы булмас.

– Икенче корылтай 2007 елда узган иде, анда милли-мәдәни оешмалар ассоциациясе Татарстан халыклары ассамблеясы итеп үзгәртелде. Аның җитәкчесе итеп Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин билгеләнде. Шуннан соң ассамблеяның статусы да күтәрелде. Милли-мәдәни оешма җитәкчеләре Татарстан Президенты каршындагы милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр буенча советы, Татарстанның Иҗтимагый палатасы әгъзалары булып тора. Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы, Мәдәният министрлыгы, Эчке эшләр министрлыгы, Федераль миграция хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе белән актив хезмәттәшлектә торабыз. Район-шәһәрләрдә Татарстан Халыклары дуслыгы йортының филиаллары эшләп килә. Татарстан Халыклары ассамблеясы утырышларында әлеге министрлык, ведомство вәкилләре дә катнаша. Һәрдаим этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча мониторинг уздырылып килә. Ике съезд арасындагы дистә елда Иҗтимагый оешмалар белән дәүләт арасында партнерлык мөнәсәбәтләре барлыкка килде. Татарстанда милли сәясәт өлкәсендә бай тәҗрибә тупланды. Шуның белән ул башкаларга үрнәк тә булып тора. Өченче съездда боларның барысы да искә алыныр, нәтиҗәләр ясалыр, киләчәккә алга таба үсәргә бурычлар куелыр дип уйлыйм. Республикада 173 төрле милләт вәкиле яши, 36сының гына үз милли-мәдәни оешмасы бар. Башкаларның да үз оешмасын барлыкка китерү, берләшү, дус гаиләгә керү теләге барлыкка килер дип өметләнәм.

ЭШ КЕШЕСЕ

Эшне сөйсәң – үз анаң...

Гап-гади эшчеләр алар, үз эшләрен яратучылар. Әлфинур Хәсбиуллинаның Казан моторлар төзү заводында эшләвенә 37 ел була икән инде, ире Илдарның эш стажы – 35 ел.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Бер урында шуның кадәр эшләп буламыни, шуңа өстәп, заводта, дип сорыйлар. Эшне сөйсәң – үз анаң, сөймәсәң – үги анаң, диләрме әле? Яратмаган эштә бер көн дә торып булмый, ә без – үз эшебезнең фанатлары, – ди Илдар абый. – Элек завод эшчеләре дип горурланып әйтә торган идек. Хәзер генә ул, эшче дигән бөек исем дигәч, елмаеп куялар. Без яшь чакта заводта эшләү зур бер абруй иде.

– Эшкә урнашу да ансат булмады, менә мине әтиемнең энесе Ямкулла абый гына сөйләшеп урнаштырды, – дип хуплый аның сүзләрен Әлфинур апа.

Аңа ул вакытта 18 генә яшь була. Тумышы белән Саба районыннан булган Әлфинур апа сигезенче сыйныфны тәмамлагач, җитен комбинатына эшкә урнаша. Башта кечкә мәктәптә укый, аннары училище тәмамлый. Бер-ике ел комбинатта тукучы булып эшләргә өлгерә. Комбинат таркалганнан соң, аны Ямкулла абыйсы моторлар төзү заводына эшкә чакыра.

– Абый анда 40 ел эшләде, безгә һәрчак, йөзне кызартырлык булмасын, намус белән эшләргә кирәк, дип әйтә иде. Бертуган Әлфия апам да шул заводта эшләде. Дүрт ел эшләгәннән соң, кияүгә чыгып, авылга кайтып китте. Заводта улыбыз Илфат та ике ел эшләп алды. Көндез автотехникумда укыды, кичке сменага заводка эшкә йөрде. Үзенә машина алыр өчен, акчаны үзе эшләп тапты. Илфат та, икенче улыбыз Илнур да автосервиста эшлиләр, икесенә дә машина «җене» кагылган. Үз эшләрен бик яраталар. Беркөнне генә исәпләп утырдык, Шәрифуллин-Хәсбиуллиннарның заводтагы хезмәт стажы – 118 ел икән.

Әлфинур апа – 16нчы цехта модельче, Илдар абый инструментлар ясый торган цехта слесарь булып эшли. Заводта танышканнар. Бер үк заводта, бер үк цехта эшләсәләр дә, бер-берләренә игътибар итмәгән дә булганнар. Мең кеше арасыннан бер-беребезне күрмәгәнбездер дә инде, ди алар. Ә танышулары ял итәргә баргач булган, ул көнне завод яшьләре җыелышып чаңгы шуган. Бернечә ай очрашып йөргәч, өйләнешеп тә куйганнар. Балалары тугач, фатирлы булганнар.

– Заводта эшләү абруй гына түгел, ул матди яктан тотрыклылык та. Хезмәт хакы яхшы булды, башка завод-фабрикаларда вакытында түли алмыйлар иде, ә бездә айныкын-айга биреп бардылар. Завод үз эшчеләренә йортлар төзеде. Аларны төзү эшендә цехтагы ирләр дә катнашты. Өч ел йортлар төзүдә катнаштым, үзебезгә фатирны үзебез салдык, – ди Илдар абый.

– Заводта эшләүне план үтәү, көне буе аяк өсте басып тору, авыр эш, начар эш шартлары дип кенә күз алдына китерәләр. Ул вакытта бик күңелле иде, заводның үз ансамбле, спорт командалары эшләп килде. Җыелышып ял итәргә йөрдек. Чаңгыда йөрү, көймәдә йөзү буенча ярышлар уздырылды. Кичке сменадан эштән кайтканда тулай торакка кереп тормыйча, пятачокта кала идек. Күңел ачып, җырлап-биеп түйгач кына кайтып ята идек, – дип сүзгә кушыла Әлфинур апа. – Кызганыч, хәзер яшьләр заводка эшкә килергә атлыгып тормый. Яшьлекләре заводта үткән буын бүген дә шунда эшли. Аларны алыштырырга яшьләр кирәк.

Хәсбиуллиннарның әйтүенчә, кеше кайда гына эшләсә дә, хезмәтен яратырга тиеш.

– Яраткан эштә генә эшләп була. Яратып эшләгән эш кенә куаныч китерә, – ди алар.

«Сәләт» белән «Талантлар университеты» берләшә

30 март-4 апрель көннәрендә «Сәләт» йортында «Сәләт – Талантлар университеты» оешмалары һәм «Сәләт»нең җәйге профильле сменалары өчен сәләтле балалар һәм яшьләрне эзләү, табу һәм аларны үстерү буенча I Халыкара биенналесы узды. Биеннале – ике елга бер тапкыр оештырыла торган фестиваль, иҗади конкурс, күргәзмә.

2017 елдан «Сәләт» – «Татарстан Республикасындагы талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы җитәкчеләренең берсе булды. Шул сәбәпле «Сәләт», «Талантлар университеты» белән бергә, «Дөнья талантлары» семинарын, «Фәнни ярышлар чемпионаты» проект конкурсын оештыра. Беренчесендә Россия буенча сәләтле балалар белән эшләүче оешмалар семинары була. Биредә сәләтле балалар белән эшләү тәҗрибәсен мәктәпләргә, югары уку йортларына җиткерәчәкләр. «Фәнни ярышлар чемпионаты» проектының максаты – фән белән мавыккан балалардан төрле бәйгеләрдә республика данын якларлык шәхесләр тәрбияләү. Проект дәвамында балалар, яшь галимнәр үзләренең фәнни презентацияләрен күрсәтәчәкләр.

yalkyn.com

– Биеннале ярдәмендә «Сәләт»нең балаларны туплауда, үстерүдә, әйдаманнарны өйрәтүдә булган 20 еллык тәҗрибәсе белән уртаклашасыбыз килде, – диде «Сәләт» фонды башкарма директоры Тимур Сөләйманов.

«Казан талантлар ачык университеты 2.0» башкарма директоры Айдар Акмаловның да сәләтләр үстерүдә үз сере бар.

– Сәләтле шәхес тәрбияләү өчен һәркемгә аерым караш булдырырга кирәк. Буш вакытларын заяга уткәрәсе килмәгән яшьләргә республика үсеш өчен һәрвакыт мөмкинлекләр, махсус программалар күп, – диде ул.

Кызганыч, Россия күләмендә төрле казанышларга ирешкән яшьләр чит илгә китү ягын карый. «Талантлар университеты», яшьләр чит җирдә тәҗрибә тупласалар да, кире республикага кайтыру яклы. Университет шуңа да чит илдә укучы, эшләүче яшь белгечләр белән элемтәдә тора. «Сәләт»тә чит илдә алган белемнәрне Татарстанда да куллану була, ди. Тимур Сөләйманов үзе дә чит илдә белем алган, бернечә телдә чиста сөйләшә.

Шырданны беләсезме?

Танылган мәгърифәтче, галим Каюм Насыйриның туган авылы Кече Шырдан авылының килеп чыгышы бик борынгы дәвергә барып тоташа. Тик ни кызганыч, авылның тарихын өйрәнүчеләр юк диярлек. Бу максаттан Каюм Насыйри туган җирен торгызу фонды яңа проект башлады. Ул тарих белән кызыксынучылар арасында фәнни-тикшеренү эшләре бәйгесе игълан итә.

Билгеле булганча, Каюм Насыйриның Зөя өязе авыллары тарихы турында хезмәте бар. Ул ел саен җәй көне авылга кайта торган булган. Вакытын Зөя өязе салалары этнографиясен, тарихын һәм археологиясен өйрәнүгә багышлаган, шифалы үсемлекләрне файдалануга кагылышлы материаллар туплаган. Фондның башкарма директоры Асия ханым Гобәйдуллина, бу авыллар тарихын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк, дип саный.

– Шырдан авылы Идел буе Болгар дәүләте таркалганчы ук барлыкка килгән, дигән фикерләр бар. Моны ничек исбатларга? 1861 елга кадәр Шырдан җирендә хаким иткән алпавытлар кемнәр алар? 1917 елдан соң авылда булган үзгәрешләрне тикшереп язучы да юк. Безнең яклар – бай тарихлы, җәмгыятьтә булган барлык вакыйгаларның шаһиты. Ел дәвамында барачак бәйгегә дип әзерләнгән материаллар авыллар тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертер иде, – ди ул.

«Кече Шырдан авылы тарихы» бәйгесендә студентлар, аспирантлар, фәнни хезмәткәрләр, укытучылар да катнаша ала. Бәйгегә эшләр 2017 елның 15 декабренә кадәр кабул ителә. Җиңүчеләр акчалата премия белән бүләкләнәчәк. Бәйгенең нигезләмәсе белән shahrikazan.com сайтында таныша аласыз.

Милли моң сакчысының берсе

Быел Тукай исемендәге Дәүләт бүләген дәгъвалаучылар (Аллага шөкер, барысы да ихтирамга лаек шәхесләр, мәгълүм иҗат әһелләре!) арасында – инде күптән җаным теләгән исемне – рухыма якын җырчым, Татарстанның халык артисты Шамил Әхмәтҗановны да күреп, бик сөендем.

Нигәме? Казахның зур шагыйре Мукагалинең (шушы көннәрдә генә Роберт Миңнуллин тәрҗемәсендә, аның татарча китабы да дөнья күрде) «Минем анкетам» дигән шигырендә, «Туган елың?» дигән сорауга ел-датасы күрсәткәч, «кордашымын Шамилнең!» – дип өстәгән. Кем икән ул Шамил? Белмим. Әмма мин шундый анкета-шигырь язсам, шагыйрьләр белән бергә танылган җырчы Шамилебезне дә әйтер идем. «Яшьтәшемен, кордашымын Шамилебезнең», – дип. Әйе, иҗаты, безнекедәй, узган гасырның 60нчы елларында ук башланган Шамил Әхмәтҗанов белән без яшьтәшләр, 41нче елгылар. Гүяки арыш басуында – изге моңнар туфрагында туып-үскән, чын милли бишек – авыл балалары без! «Кайда да йөрәктә, төшләргә кереп гел йөдәтә Кырлай яклары» дип юкка гына җырламый Шамил. Әйе, ул Арча ягыннан, мәгърифәтче муллалар һәм атаклы көрәшчеләр белән дан тоткан Курса Почмак авылыннан. Тукай туган як бу, Курсавилар, Мәрҗаниләр, Камаллар чыккан төбәк. Шул данлы якташлары кебек, бүген халыкка танылу өчен, әлбәттә, алар рухын, моңын тоярга, дәвам итәргә, гомереңне шул юлга багышларга кирәк! «Бер генә аның шарты!» – ди бу турыда шагыйребез Сибгат Хәким, якташларының дәвамын күзаллап. Бөек миссия бу! Җырда да шулай. Сүз җаеннан әйтик, Сибгать ага Шамилне якын итә иде: иҗатын хуплап, мәкаләләр язды, киңәшләр биреп, уңышлары өчен сөенеп яшәде, иҗат кичәләренә чакырды. Бергә Күлле Кимегә кайтулар әле дә истә. Шагыйрь сүзләренә язылган җырларны башкарган Шамилнең моң аһәңнәре дә хәтердә. Тукаебыз сүзләренә җырлана торган җырлар да колагымда Шамил тавышы белән яңгырый: «Туган җиремә», «Зиләйлүк», «Әлвидагъ», «Өзелгән өмид...» һ.б. Сибгат Хәким сүзләренә «Бик сагынган чаклар була сине, Тукай» җыры да Тукайга бәйле. «Син чыгасың, әнкәй, коега» җыры да (Сибгат Хәким сүзләренә) халыкчан моң белән өретелгән. Чын безнеңчә матур милли көйләр, билләһи! Шамилнең ягымлы тембрлы баритон тавышы, ачык дикциясе, салмак эчке бер илаһият белән тәэсир итә торган интонацияләр, милизмы – барысы да шул вакыйгалардан алып күңелне әсир иткән, мөгаен. Җырчы белән күп кенә авылларда да йә Казанда узган шигырь, җыр кичәләрендә бергә чыгыш ясарга туры килде. Һәм аның уңышларының шаһиты булу бәхете дә тиде ул чакларда: гади халык мәхәббәте белән бергә төрле җитәкчеләрнең, ил агаларының, хәтта Илбашының да яратып кабул итеп, җырчыга ихтирамлы мөнәсәбәтен күреп, Шамил өчен һәрчак горурлык тойдым. Шулай, шагыйрьләр белән җырчылар дуслыгы да Тукай чорыннан ук килә бит: барыннан да бигрәк Моң өчен, халыкчан башкару мәктәбе, шул юлда бөек Илһамнар янәшәсендә үз йөзен югалтмаган чын табигый тавыш ияләре өчен горурлык хисе ул.

25 яшеннән башлап, җырчының хезмәт урыны – Татарстан җыр һәм бию дәүләт ансамбле. Татар исемен – моңын, рухын бар дөньяга таныту еллары бу. Үзе бер милли тарих булган – ансамбльнең эшчәнлегенә багышланган китапны укыганда да (моның өчен якташым Филүсә Арслановага рәхмәтлемен) Шамил өчен горурлык хисе ташламады: ул – ансамбльнең солисты, дуэт белән дә гаҗәеп матур язмалары калган (Ания Туишева белән бергә башкарган «Ак пирчәткә», «Галиябану»), «Таһир-Зөһрә» һ.б. искә төшерик. Ә халык җырларыннан инде Шамил башкаруында «Арча», «Сивай кашка», «Мөһаҗирләр», «Әрәмә», «Син дә җаныемның хәсрәтеннән», «Алма бакчасы», «Габделхәй» кебекләрне аерым әйтер идем. Алтын фондка кергән җырлар дип саныйм мин аларны. Җырчының 75 җырдан торган соңгы аудиодискында алар күп – җаның теләгәнен тыңла.



ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТ

Ә инде Шәриф Хөсәенов сүзләренә Рөстәм Яхин язган атаклы «Сорнай җыры» ансамбль белән ярты дөньяны гизгән. Нинди генә илләрдә алкышламаганнар Шамилне ул җыр өчен: Германия, Төркия, Япония, Италиядә, Африка... Ә Мәскәүдә? Югары сәнгать белгечләре нәкъ шунда олуг бәясен бирә җырчыбызга... һәм, әлбәттә, ансамбльгә. Рөстәм Яхинның башка җырларын да Мансур Мозаффаров, Сара Садыйкова,Фасил Әхмәтов, Мирсәит Яруллин әсәрләрен дә башлап җырлау бәхете тия Шамилгә һәм ул әле мәгълүм «Аулак өй» исемле вокаль-хореография спектаклендә (Нәкый Исәнбәт әсәре буенча куелган) җор, шаян Бабайролендә дә 25 ел буе уйнап, танылу ала. Ә 1998 елда Түбән Новгородта узган халык җырларын башкару бәйгесендә (жюри рәисе Илһам Шакиров үзе!) лауреат исеменә лаек була. Җырчы бүген дә Моң илендә. Филармониядә вокал буенча репетитор. Яшь җырчыларның остазы. Шәкертләре – Рамил Миңнегалиев, Илнур Нуриев, Аршак Алтуняннар инде үзләре төрле конкурсларда җиңү яулаган сәләтле яшь талантлар. Әмма иң сөйгән укучысы – кече кызы Чулпан Әхмәтҗановадыр, мөгаен. Татарстанның атказанган артисты ул. Әтисенең юлын дәвам итүче җырчы. Өлкән кызы Гөлнар да музыкант-композитор. Менә шундый милли-музыкаль гаилә бар Казанда.

Халыкның рухы-күңеленең «рушан көзге»сен һәм туган телне нәкъ Тукай өйрәткәнчә аңлап, саклап, киләчәккә алып бара торган үрнәк мәктәп түгелмени бу иҗат?! Ә җыр дигән, моң дигән төшенчәләрнең әнә шундый сыналган, халыкчан традицияләргә таянуын еш кабатлап тору зарурдыр. Бигрәк тә бүгенге вазгыятьтә.

Рәдиф ГАТАШ,
Татарстанның
халык шагыйре.

ПОЧТАДАН

Безнең китаплы Сөләйман

Җитте шундый заман: татарның теле бетә дип оран сала башладылар. Их идрит-кудрит, тормышка керде шул интернет. Имеш, газета-журналларның көне санаулы гына, китаплар да, имеш, калыр чүплектә... Ашыкмасыннар! Андый көнгә калмабыз.

Әнә Сөләйман Шакиров шалтырата, белеп торам, яхшы хәбәр әйтәчәк ул миңа. Театрларга йөрергә ярата ул. Әле «Җанкисәккәем»не, әле «Зәңгәр шәл»не, әле кичә генә «Җилкәнсезләр»не карарга чакырган иде. Бу юлы «Казан» милли мәдәният үзәгендә китап күргәзмәсе була дип җиткерде.

Сөләйман белән күптәнге дуслар: 1нче трестта 33 ел бергә эшләдек, 15 еллап Казан Аксакаллар шурасында фикердәшләр булып аралашабыз.

Сөләйман Шакиров «Тормыш мизгелләре» дигән китабын бастыргач, берничә көнгә дип кенә миңа укырга биреп торган иде. Өченче көн киткән икән, ярый әле укырга өлгердем. Шуны эләктердем дә йөгердем.

Сөләйман кордаш мине, вәгъдә иткәнчә, ишек төбендә каршы алды. Рәхмәт әйтеп, китабын тапшырдым. Тиражының 99ын туганнарына, Әлки төбәгендәге «Хузангай» хуҗалыгы җитәкчеләренә, китапханәләргә бик тиз таратып бетергәнгә, үзенә дә шул гына калган икән.

Залга уздык. Кулына китабын тоткан килеш, Сөләйман буш калган урынга килеп утырды. Урыннарыбыз өлкән журналист-язучы Азат Сөнкишев янәшәсенә туры килде. Сөләйманга Алиш баба онычы – Абдулла Алишның кардәш туганы: «Син кем?» – дип сорау бирде.

– Сөләйман пәйгамбәр булган бит, – диде дустым. – Мин китаплы Сөләйман булам.

Болай дип әйтергә хокукы бар шул аның. Китап язу, бастыру хәлләренең ничеклеген миңа сөйләде ул. Китабына да язган. Әлки районы Татар Төгәлбаенда туган ул. Шунда егет булып җитлеккән. Казанга барып укып кайтканнан соң туган авылында һәм Моркваши ял йортында халыкка кино күрсәткән. Хәтта авылларында клуб мөдире дә булган әле. 60-90нчы елларда Казандагы КПД – 1 заводында эшләгәндә, Сөләйман да хезмәттәшләре белән ярты Казанны төзеште. Китап язарлык багажы бар, диюем. Шуңа күрә дә Сөләйман кордашның әлеге китабы үзенең лаеклы бәясен алыр дип ышанам, чөнки аның Шакировлар гаиләсе өчен генә язылмавы күренеп тора.

Әлеге китапта Түбән Новгород өлкәсенең Сергач төбәгендәге бер авылында үткәрелгән татар Сабан туе турында матур хикәя бар. Сөләйман бу авылны, андагы кешеләрне барып күргәч, фотоларын да урнаштырган, чөнки бу авылда ул яраткан Хәсибә исемле кыз үскән. Һәм аның гомерлек яры булган. Алар бергә-бергә шул Сабан туйларын күреп йөргән. Ул үз китабында туган төбәге Әлкидәге Актай, Бизнә елгаларын, челтерәп аккан чишмәләрен, Салман, Чаллы, Әлки авылларын да яратып тасвирлаган. Аның өчен киң Ватаныбыздагы бөтен җир – газиз. Андагы чуаш, урыс татар авыллары дисеңме, барысы да күңеленә якын. Ул яхшы гамәл кылган бар кешене дә ярата, хөрмәт итә.

Нәрсә әйтим, бер утыруда рәхәтләнеп укый алырлык китап язган быел 80 яшен түгәрәкләүче дустым. Үзенә генә түгел, Казан аксакалларының күбесенә, милләттәшләренә дә әлеге китабы белән матур бүләк ясаган кордаш. Рәхмәт үзенә!

Рәис ИДРИСОВ.

Өметле композитор

Казанда язучы Василий Аксенов музеенда төрле әдәби кичәләр, концертлар уза. Шундыйларның берсе композитор Рушания Ниҗәметдиновага багышланган иде.

Яшь композитор Рушания Ниҗәметдинова Мәскәү консерваториясен тәмамлаган. Аның әсәрләре Казан, Санкт-Петербург, Германия, Бөекбритания, Испания һәм Мәскәүдә халыкара фестивальләрдә яңгырый. Бүгенге көндә ул электроакустик һәм акусматик музыка белән шөгыльләнә, музыка мәктәбендә укыта. Кичәдә дә аның әсәрләрен халыкара конкурслар лауреатлары, Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентлары башкарды. Шагыйрь, журналист Айрат Бик-Булатов үзенең шигырьләрен укыды.

Равилә МӨБАРӘКШИНА.

«Калеб»кә «канат» кирәк

«Калеб» яңа буыны җыены өчен апрель ае вакыйгаларга бик бай ай булырга охшап тора. 2 апрельдә алар Химиклар мәдәният сараенда Тукайның «Сәрләүхәсез» (Исемсез) шигыренә нигезләнгән вербатим тәкъдим итте, ә киң җәмәгатьчелек шушы ук спектакльне 14е көнне Камал театрының кече сәхнәсендә күрә алачак.

27 апрельдә исә Луиза Янсуар иҗаты буенча «Ишек» поэтик спектакле куелачак. Шулай ук проза буенча «Үз юлым» конкурсы да дәвам итә, дип белдерде оешманың җитәкчесе Гүзәл Сәгыйтова журналистлар белән очрашу вакытында.

Безнең колакка ятрак булып яңгыраган вербатим – документаль театр дигәнне аңлата.

– Без тамашачы белән аралашуның яңа төрле ысулларын эзлибез. Һәм вербатимны да мин яңалык дип атыйм. Дәүләтнең татар театрлары балаларга рус телендә спектакльләр куярга мәҗбүр. Моңа кем гаепле? Ни өчен ана теленә игътибар юк? Милләт мәсьәләсендә безгә берләшергә вакыт җиткәндер. Әле соңга да калмадык микән? Казанда тәкъдим ителәчәк яңа юнәлештәге иҗатыбыз аша нәкъ менә шушыларны ачыкларга тырыштык. Тел, милләт язмышы турында һаман-һаман сөйләшергә кирәк, чөнки татар теле, горурлык хисләре безнең каныбызга сеңгән. Шушы проект турында ишеткән яшьләр: «Әйдәгез, эшлик», – дип киләләр икән, димәк, безнең өмет бар әле, – ди проектның режиссеры Нәфисә Исмәгыйлева.

Вербатимга материалны актерлар үзләре үк 20-40 яшьлек туганнары, танышлары арасыннан интервью рәвешендә туплаган. Алар арасында эшмәкәрләр дә, укытучылар да, студентлар да бар. Спектакльдә җавап бирүчеләрнең бер генә сүзе дә, җөмләсе дә үзгәртелмичә, ничек алынган – шулай тәкъдим ителгән. Әмма реаль геройлар булса да, аларның исемнәре әйтелми.

Шунысы ачык: тамашачы сәхнәдә традицион спектакль күрергә өметләнеп килмәсен. Гүзәл Сәгыйтова: «Гадәттә «Калеб» кичәләреннән кеше спектакльне аңламыйча кайтып китә», – дисә, Нәфисә Исмәгыйлева:

– Иманыл камил, бөтен кеше дә аңлаячак, спектакль күңелсез булмаячак, чөнки әлеге монологларның һәрберсе бик гыйбрәтле. Алар һәр татар кешесенең күңеленә үтеп керәчәк. Ягъни бүген яшьләр татар теле турында ни уйлый, сүз шул турыда барачак. Бу спектакльне җаны булган кеше барыбер аңлаячак. Без сораулар куйдык, аңа җавапны төрле кеше төрлечә бирәчәк, – ди.

Рус кешесенең монологын гәүдәләндерүче Рәдиф Кашапов та, режиссерның фикерен куәтләп:

– Вербатимның кискен борылышы да, чишелеше дә бар. Аннан соң ике яклы фикерне каракаршы куеп бирергә тырыштык. Минем герой – ике телдә дә яхшы аралашучы рус егете, – ди.

Вербатимга көйне консерватория студенты Зөлфәт Вәлиуллин язган.

– Мондый проектлар бик аз һәм композиторларга үзләрен күрсәтергә мөмкинчелек юк. Шуңа күрә әлеге проекта катнашырга чакырулары өчен, «Калеб»кә бик зур рәхмәтлемен. Әлеге спектакльдә музыка үзенә артык зур игътибар таләп итми. Монда ул ярдәмче ролендә генә, – ди.

Гүзәл Сәгыйтова әйтүенчә, «Калеб»нең проектлары, идеяләре бик күп. Әмма аларның барысын да тормышка ашырыр өчен мәйдан һәм финанс яктан ярдәм кирәк.

– Русларның мәйдан учаклары бар бит. Без бүген репетицияләр өчен дә кул сузып, мәйдан бирегез инде, дип сорап йөрергә мәҗбүр. Ярый әле, Язучылар берлеге бар. Шактый репетицияләребез аларның бинасында уза. Без дә бит үз Татарстаныбызда кечкенә генә булса да мәйданчыгыбызга лаекбыз? Яшьләрнең әллә ни кадәр оешмалары бар, аларга мөмкинлек кенә кирәк, кайвакыт бер елмаю да җитә, без канатланып эшләргә әзер. «Калеб»кә башка дәрәҗәгә чыгарга вакыт җитте. Үз мәйданыбызны булдырумы ул, ниндидер проектларны финанслаумы... Бездә талантлы яшьләр бик күп, әмма алар инде арыды, шуның өчен башка дәрәҗәгә чыгып, канатлар куясы килә, – ди Гүзәл Сәгыйтова.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

«Созвездие — Йолдызлык» XVII ачык республика телевизион яшьләр эстрада сәнгате фестиваленең сайлап алу турлары тәмамланды. Иң яхшы чыгышларны 14 апрельдә – УНИКС концертлар залында, 22 апрельдә «Пирамида» мәдәни күңел ачу үзәгендә күреп булачак.

«Йолдызлык» – тансык кунак

1 февраль-31 март аралыгында Казан, Баулы, Буа, Нурлат, Түбән Кама, Чаллы, Яшел Үзән шәһәрләрендә, Актаныш, Әтнә, Балык Бистәсе районнарында 21 меңнән артык бала җыр, бию, нәфис сүз буенча көч сынашты. «Созвездие - Йолдызлык»ның генераль продюсеры Дмитрий Туманов: «Фестивальнең суперфинал өлешендә балаларны бәяләүче жюри әгъзаларын кызганам», – ди. Аларга бу юлы көненә 300ләп номерны карап бәяләргә туры киләчәк.

–«Созвездие — Йолдызлык» Татарстан өчен язның иң күркәм вакыйгаларының берсе. Хөкүмәтебез дә аны югары бәяли. 2006 елдан фестивальнең Гран-при иясенә 70 меңлек стипендия тапшырыла. Барлыгы 35 акчалата стипендия каралган. Иң-иңнәре ГИТИС Россия театр сәнгате университетында белем ала. Биредә инде 22 кеше укып чыкты, хәзерге вакытта тагын 26 бала укый, – диде Татарстан Республикасының яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары Рөстәм Гарифуллин.

Татарстанда калырга теләүчеләр өчен Нәҗиб Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе ишекләре ачык. Биредә инде ун кеше академик вокал нигезләренә төшенгән.

«Созвездие — Йолдызлык» өстәмә белем бирүче укытучыларның да дәрәҗәсен күтәрә.

–Сәләтле остаз булмаса, сәләтле балалар булмас иде. «Йолдызлык» – өстәмә белем бирү юнәлешендәге иң яхшы проект. Шуңа да җиңүчеләрне әзерләгән укытучыларны грантлар һәм стипендияләр белән бәялибез. «Балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә иң яхшы укытучы» дигән 30 меңлек 50 грант бүләк итәбез, – диде Татарстан Республикасының мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима.

Быел фестивальдә катнашучы балалар бакчалары да арткан.

– «Йолдызлык»та катнашучы балаларга сокланып туя алмыйм, алар мине гел шаккатыра. Балаларның чыгышын бәяләү бик авыр. Безнең ялгышырга хакыбыз юк. Сабыйлар сәхнәгә бәхетле булып чыгарга тиеш, – диде Россиянең халык артисты, фестивальнең жюри рәисе Зилә Сөнгатуллина.

– Район җитәкчеләре фестивальгә костюмнарны 10 миллион сумнан да кимрәкккә тектерми. Ә зона этабын үзендә оештыру өчен, районнар арасында чып-чын ярыш бара, – ди Лариса Сулима.

Республика бюджетына килгәндә, фестивальгә 80 миллион сумга төшә. Дмитрий Туманов белдерүенчә, бу бер дә зур сан түгел.

–Чагыштырып карыйк: «Президент чыршы бәйрәме» бер көн оештырыла – аңа 28 миллион 500 мең сум акча тотыла. Без «Йолдызлык»ның бюджеты «Рубин» уенчысының бер айлык хезмәт хакына кадәр генә булса да җитсен иде, дип хыялланабыз, – ди ул.

Быел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, «Созвездие–Йолдызлык» яшьләр музыка театрын төзекләндерү өчен, 150 миллион сум акча бүлеп бирде. Сәләтле яшьләргә республикада иҗат итәргә бер этәргеч булачак, ди Дмитрий Туманов.

Алисә САБИРОВА.

Балалар спорты үсеш алачак

Табиблар гына түгел, Дәүләт Думасы депутатлары да чаң суга: бүген балаларның бары ун проценты гына тулысынча сәламәт, нарасыйларның яртысыннан артыгы хроник авырулардан интегә. Балаларның физик әзерлек дәрәҗәсе соңгы чиккә җиткән. Шул максаттан Идел буе федераль округында «Балалар спорты» федераль проекты старт алды.

Проект 2017 елдан алып 2022 елга кадәр тормышка ашырылачак. Программа сәламәт яшәү рәвешенә, мәктәпләрдә физик тәрбия бирүне камилләштерүгә, спорт заллары һәм спорт сарайларын үзгәртеп коруга юнәлтелгән булачак. Программа кысаларында зур ярышларда катнашучы балалар спорт йолдызлары белән аралашачак.

– Бу юнәлештә лидер булырга телибез. Федераль проект белән бергә «Безнекеләр өчен җан ат» программасы эшли башлады. Ул авыр тормыш хәлендә калган һәм мөмкинлекләре чикле балаларга юнәлтелгән, – ди Россиянең Дәүләт Думасы депутаты, проектның төбәк координаторы Ольга Павлова.

Кадастровым инженером Кутдусовой Натальей Генадьевной (СНИЛС №128-830-216 57), являющейся членом СРО АКИ «Поволжье» (номер в Гос. реестре СРО «009», дата вступления 05.07.2013 г.), квалификационный аттестат №16-11-417, адрес: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1, адрес электронной почты: m2405085@yandex.ru, тел. 8(843)2405085, в отношении земельного участка с кадастровым номером, расположенного по адресу Республика Татарстан, г. Казань, Приволжский район, п. Алтан, уч. 212, выполняются кадастровые работы по образованию земельного участка.

Заказчиком работ является Залялова Гульсинур Ахатовна (422036, РТ, Арский район, с. Шушмабаш, ул. Такташа, д. 10, тел. 89872969515). Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования границ состоится по адресу: 420141, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1 05.05.2017г. в 10:30минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: 420141, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1. Обоснованные возражения относительно местоположения границ , содержащихся в проекте межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с ежедневно с 9 до 17 часов с 4 апреля до 4 мая 2017 года по адресу: 420141, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Салиха Батыева, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ 16:50:160713:1,16:50:160713:2, 16:50:160713:3 и 16:50:160713:12. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

31 март-2 апрель көннәрендә Казанда суга сикерү буенча ФИНАның Дөнья сериясе ярышлары барды. Дөнья сериясен Татарстан башкаласы инде өченче тапкыр кабул итә. Моңа гаҗәпләнерлек тә түгел, чөнки ФИНА вәкилләре өчен без – үрнәк спорт шәһәре.

Сикереп тә күрсәттеләр!

Алисә САБИРОВА

Халыкара йөзү федерациясе президенты Хулио Маглионе: «2015 елда Казанда узган Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты тарихта иң яхшы чемпионат булды», – дип искә ала.

– Мин Казанга, Татарстанга кабат кайтуыма шат. 2015 елда без монда ФИНАның иң яхшы чемпионатын кабул иттек. Әлеге ярышлар спорт объектлары һәм оештыручыларның тырышлыгы аркасында югары дәрәҗәдә үтте. Бүген без искиткеч бассейнда ярышлар күзәтәбез. Килгән саен, ул тагын да яхшыра, – диде ул.

Аның сүзләрен Халыкара йөзү федерациясенең башкарма директоры Корнель Маркулеску да әләктереп алды.

– Казанга шушы спорт сараена кайтуыма шат мин. Кызганыч, Казанда Конфедерация Кубогы үткәнгә, су полосы буенча суперфинал ярышларын кабул итә алмыйбыз. Инде дөнья сериясендә катнашачак спортчылар белән аралашып өлгердем, алар биредәге шартлар белән канәгать. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка су спорты төрләрен яратуы, аларны һәрвакыт үстерүе өчен рәхмәтлемен, – диде Корнель Маркулеску.

Дөнья сериясе ярышларында спортчылар 3, 10 метр биеклектәге трамплиннан ялгыз, синхрон һәм катнаш (микс) сикерү буенча ярышалар. Барлыгы 13 илдән 70 спортчы килгән иде. Нәтиҗәдә 9 – алтын, 4 – көмеш, 4 бакыр медаль алып, Россия өченче урынга ия булды. Беренчелектә – Кытай (15,10,10), икенче урында – АКШ (13, 14, 6). Казанлылар көтеп алган Татарстан спортчысы Никита Шлейхер, сәламәтлеге начарлану сәбәпле, ярышларда катнаша алмады.

Суга сикерү буенча Россия җыелмасы баш тренеры Светлана Моисеева белдерүенчә, бу ярышларга команда җину өчен килмәгән.

– Максатыбыз югары күрсәткечләр түгел иде. Спортчылар биредә Дөнья чемпионаты алдыннан суга сикерү осталыкларын шомартты. Шундый дәрәҗәдәге ярышларның Россиядә узуы куандыра, бу – спортчылар өчен бик мөһим, – диде тренер.

Гаҗәеп ярышлардан тыш, Дөнья сериясе Казанга «табадан төшкән» яңалыклар да алып килде әле.

Россиянең суга сикерү һәм синхрон йөзү буенча федерациясе президенты Алексей Власенко сүзләренчә, безнең илдә Су спорты төрләре ассоциациясе барлыкка киләчәк. Ә аның үзәге дип Казан билгеләнәчәк.

Сүз уңаеннан, Татарстан 2016 елда спорт чараларын оештыру буенча Россия регионнары арасында икенче урынга ия булды. Беренче урынны без Кышкы Олимпия уеннарын кабул иткән Краснодар краена оттырдык.

Шулай ук 2015 елда Спортның су төрләре буенча дөнья чемпионаты вакытында казанлыларны шаккатырган хай-дайвинг (27 метр биеклектән сикерү) ярышлары Олимпия уеннары программасына керергә мөмкин. ФИНА Халыкара олимпия комитетына әлеге спорт төрендә микс-дисциплиналарда медальләр санын арттырырга кирәк, дигән фикер белән мөрәҗәгать итмәкче. Ачык суда марафон аралыгын йөзгәндә, катнашучылар санын 25тән 35 кешегә җиткерү карары да яңгырады.

Дөнья спорты Россиядән йөз чөергән вакытта, ФИНАның безгә карата мөнәсәбәте сөендерә. Халыкара олимпия комитеты Россиядә зур спорт чаралары үткәрүгә каршы булуга карамастан, Россия белән алга таба да эшләячәкбез, ди ФИНА вәкилләре.

– Россиянең Су спорты төрләре федерациясе белән булган мөнәсәбәтләребез нык һәм дустанә. Россия белән эшчәнлекне дәвам итәбез, – диде Корнель Маркулеску.

Халыкара йөзү федерациясе карамагы астында үткәрелә торган Дөнья сериясенә 2007 елда нигез салына. Ярышларны Бөекбритания, Кытай, Мексика илләре Су спорты федерацияләре башлап җибәрә. Соңрак бу илләргә Канада, Катар, Россия һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләре дә кушыла. Гадәттә, бу ярышларда Олимпия уеннары призерлары, дөнья чемпионнары кебек спорт элитасы катнаша.

Фотолар ria.ru агентлыгыннан алынды.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562–50–12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562–50–03,
E–mail: shahri–kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1642. Гомуми тираж – 6179.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 696. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77– 50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562–50–12,
факс: (843) 562–50–07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы